| | | |
|---|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СПАССКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**№ 248** **12 апрель 2019 ел**

Җирлекләрнең чыгым йөкләмәләрен
үтәүне финанслар белән тәэмин итү өчен
Татарстан Республикасы
Спас муниципаль районы җирлекләре
бюджетларына
“Спас муниципаль районы”
муниципаль берәмлек бюджетыннан
башка бюджетара трансфертлар бирү
тәртибен раслау турында

Һөнәри керемгә салым буенча салым потенциалын арттыруны стимуллаштыру максатында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 28.03.2019 елгы «Муниципаль берәмлекләрнең чыгым йөкләмәләрен үтәүне финанслар белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» №233 карары нигезендә, Башкарма комитет КАРАР БИРӘ:

1. Җирлекләрнең чыгым йөкләмәләрен үтәүне финанслар белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы җирлекләре бюджетларына “Спас муниципаль районы” муниципаль берәмлек бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен расларга.

2. Шушы карарны контрольдә тотуны Спас муниципаль районы Финанс-бюджет палатасына йөкләргә.

Башкарма
комитет җитәкчесе В.А.Осокин

Спас муниципаль
районы Башкарма
комитеты карары белән
расланган
12.04 2019 № 248

**Җирлекләрнең чыгым йөкләмәләрен үтәүне финанслар белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы җирлекләре бюджетларына “Спас муниципаль районы” муниципаль берәмлек бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибе**

1. Әлеге тәртип «Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджетыннан Спас муниципаль районы җирлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү механизмын билгели (алга таба – башка бюджетара трансфертлар).

2. Җирлекләр бюджетларына башка бюджетара трансфертлар һөнәри керемгә салым буенча салым потенциалы үсешен стимуллаштыру, җирлекләрнең чыгым йөкләмәләрен үтәүне финанс ягыннан тәэмин итү максатларында максатларында бирелә.

3. Башка бюджетара трансфертлар Татарстан Республикасы бюджетыннан әлеге максатларга кергән бюджет ассигнованиеләре күләме чикләрендә узган кварталдан соң килүче айның 30 числосына кадәр квартал саен бирелә.

4. Әлеге Тәртип нигезендә бирелә торган бюджет акчаларын төп бүлүче булып Спас муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы (алга таба – финанс-бюджет Палатасы) тора.

5. Башка бюджетара трансфертларны бүлү Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан раслана.

6. i-нче җирлек өчен тиешле кварталга башка бюджетара трансфертлар күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$МТ_i^{кв} = СМТ_i^{год} – СМТ_i^{пт},$$

кайда:

$МТ_i^{кв}$ – i-җирлеккә тиешле квартал өчен башка бюджетара трансфертлар күләме, сум;

$СМТ_i^{год}$ – ел башыннан арта барган нәтиҗә белән Татарстан Республикасы бюджетыннан кергән бюджетара трансфертлар суммасы, сум;

$СМТ_i^{пт}$ – элгәре башка бюджетара трансфертлар бирү максатларында исәпкә алынган i-җирлек бюджетына кергән бюджетара трансферт суммасы, сум.

7. Бюджетларга башка бюджетара трансфертлар бирү шарты белән башка бюджетара трансфертларны бирү шартларын күздә тоткан Спас муниципаль районы авыл җирлекләре арасында башка бюджетара трансфертлар акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла торган чыгымнарның юнәлешен билгели торган норматив хокукый акт булу.

8. Башка бюджетара трансфертлар Финанс-бюджет палатасы тарафыннан җирлекләр бюджетларына җирле бюджетларның үтәлешенә касса хезмәте күрсәтү өчен ачылган Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсенең территориаль органнары счетына күчерелә.

9. Җирлекләрнең башкарма комитетлары (алга таба – башкарма комитетлар) Финанс-бюджет палатасына форма буенча һәм финанс-бюджет палатасы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә башка бюджетара трансфертлардан файдалану турында отчет тапшыралар.

10. Әлеге Тәртип нигезендә алынган, агымдагы финанс елның 1 гыйнварына кадәр кулланылмаган башка бюджетара трансфертлар агымдагы финанс елының беренче 15 эш көне эчендә Спас муниципаль районы муниципаль берәмлеге бюджеты керемнә кире кайтарылырга тиеш.

Отчеттагы финанс елында файдаланылмаган башка бюджетара трансфертларга ихтыяҗ булу турында Финанс-бюджет палатасы карары нигезендә, әлеге башка бюджетара трансфертларның калдыкларыннан артмаган күләмдә, акчалар агымдагы финанс елында моңа кадәр алар бирелгән җирлек бюджетының башка бюджетара трансфертлар бирүнең тиешле максатларына туры килә торган чыгымнарын финанс ягыннан тәэмин итү өчен җирлек бюджеты керемнә кире кайтарылырга мөмкин

Әлеге Тәртип нигезендә алынган башка бюджетара трансфертларның файдаланылмаган калдыклары «Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджеты керемнә күчерелмәгән очракта, әлеге акчалар Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләрне үтәп, Финанс-бюджет палатасы тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә бюджет керемнә алынырга тиеш.

11. Законнар нигезендә, тапшырыла торган отчет мәгълүматларының дөрес булмавы һәм башка бюджетара трансфертлар бирү шартларын үтәү өчен Башкарма комитетлар һәм җирлекләрнең вазыйфаи затлары җаваплы.

12. Башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары бозылган очракта, Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнгән тәртиптә тиешле акчалар «Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджеты керемнә күчерелергә тиеш.

13. Әлеге Тәртип нигезендә бирелгән башка бюджетара трансфертларның максатчан кулланылышын контрольдә тотуны Финанс-бюджет палатасы гамәлгә ашыра.